# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Биектау муниципаль районы составына керүче “Биектау авыл җирлеге” һәм “Красносельский авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

Биектау муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп корырга:

1) әлеге Законның 1 статьясында каралган үзгәрешләрне исәпкә алып билгеләнгән чикләрдә “Биектау авыл җирлеге”н һәм “Пермяк авыл җирлеге”н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Биектау авылы булган “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенә берләштерү юлы белән;

2) “Бөреле авыл җирлеге”н һәм “Сосновка авыл җирлеге”н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Бөреле җәнлек совхозы поселогы булган “Бөреле авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенә берләштерү юлы белән;

3) “Каенлык авыл җирлеге”н, “Чыршы авыл җирлеге”н һәм “Шуман авыл җирлеге”н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Каенлык авылы булган “Каенлык авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенә берләштерү юлы белән.

**3 статья**

1. Яңа төзелгән “Каенлык авыл җирлеге”, “Бөреле авыл җирлеге”, “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләренең (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр) беренче чакырылыш вәкиллекле органнары депутатларының һәм беренче башлыкларының вәкаләтләре чорын ике ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән “Каенлык авыл җирлеге” һәм “Бөреле авыл җирлеге” муниципаль берәмлекләренең беренче чакырылыш вәкиллекле органнары депутатлары санын ун кеше, яңа төзелгән “Биектау авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең унбиш кеше тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм үткәрү законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**4 статья**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумнарда кабул ителә торган яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарларда башкасы билгеләнмәгән булса, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән һәрбер муниципаль берәмлекнең беренче башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлап куела.

Яңа төзелгән һәрбер муниципаль берәмлекнең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты, вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән саныннан яртысыннан артыграгы аны хуплап тавыш бирсә, бу муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы дип санала.

Яңа төзелгән һәрбер муниципаль берәмлек башлыгын сайлап куйганчы, бу муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары утырышларын вәкиллекле органның яше буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара;

2) яңа төзелгән һәрбер муниципаль берәмлекнең сайлап куелган башлыгы бу муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**5 статья**

“Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм

аларның статусы турында” 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2007, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2008, № 12 (VI өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“**2 статья.** “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләренең чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 3 – 31 нче кушымталар) нигезендә билгеләргә, аларга авыл җирлеге статусын бирергә һәм административ үзәкләрен билгеләргә:

Айбаш авыл җирлеге: Айбаш (административ үзәк), Олы Көек, Яңавыл, Апсабаш, Каракүл, Кодаш авыллары;

Алан-Бәксәр авыл җирлеге: Алан-Бәксәр (административ үзәк), Алат спирт заводы, Гәр, Әсән, Шөмлән авыллары;

Әлдермеш авыл җирлеге: Әлдермеш (административ үзәк), Сая, Өбрә авыллары;

Каенлык авыл җирлеге: Каенлык (административ үзәк), Өнсә, Аяз Иле, Чыршы, Шуман, Абла, Бәерле, Олы Пүчинкә, Кече Пүчинкә, Олыяз, Соловцово, Тимофеевка авыллары;

Бөреле авыл җирлеге: Бөреле җәнлек совхозы поселогы (административ үзәк), Пимәр, Сосновка, Керосиново, Кирилловка авыллары, Бөреле тимер юл разъезды поселогы;

Олы Битаман авыл җирлеге: Олы Битаман (административ үзәк), Биғнарат, Кече Битаман, Ювас авыллары;

Олы Кавал авыл җирлеге: Олы Кавал (административ үзәк), Чуаш Иле, Мажар, Кече Кавал авыллары;

Биектау авыл җирлеге: Биектау (административ үзәк), Пановка, Пермяк, Калинино, Келәтле, Эстачи авыллары, Инеш поселогы;

Дачный авыл җирлеге: Дачный поселогы (административ үзәк), Яшь Көч авылы;

Дөбъяз авыл җирлеге: Дөбъяз (административ үзәк), Олы Солабаш, Кече Солабаш, Таршна, Торнаяз, Шыпшыек авыллары;

Иске Казан авыл җирлеге: Коркачык (административ үзәк), Камай, Татар Әйшәсе, Югары Ия, Кызылкүл, Рус Урматы, Татар Урматы авыллары;

Казаклар авыл җирлеге: Казаклар (административ үзәк), Өлә, Матмыр, Наратлык авыллары;

Красносельский авыл җирлеге: Биектау тимер юл станциясе поселогы (административ үзәк), Березовка, Яңа Поселок, “Каменка” шифаханәсе, Урманчы поселоклары, Киндерле тимер юл разъезды поселогы;

Коркачык авыл җирлеге: Коркачык тимер юл разъезды поселогы (административ үзәк);

Мәмдәл авыл җирлеге: Мәмдәл (административ үзәк), Юртыш поселогы;

Мүлмә авыл җирлеге: Мүлмә (административ үзәк), Красна, Сасмак, Тимерче авыллары, Кызыл Болгар поселогы;

Алат авыл җирлеге: Рус Алаты (административ үзәк), Кече Алат, Потаниха, Урта Алат авыллары;

Семиозерка авыл җирлеге: Семиозерка (административ үзәк), Шигали, Макаровка, Теплый Ключ авыллары, Күлле, Якты Күл поселоклары;

Суыксу авыл җирлеге: Суыксу (административ үзәк), Олы Рәс, Кондырлы, Кече Рәс, Ташсу, Чәмәк авыллары;

Ташлы Кавал авыл җирлеге: Ташлы Кавал (административ үзәк), Глухово, Рус-Татар Әйшәсе, Туктамыш, Өмбе авыллары;

Усад авыл җирлеге: Усад (административ үзәк), Хохлово, Ильино, Садилово, Толмач, Тимофеевка, Чубар авыллары;

Чыпчык авыл җирлеге: Чыпчык (административ үзәк), Байкал, Кече Бөреле, Зур Бөреле авыллары;

Чернышевка авыл җирлеге: Чернышевка (административ үзәк), Каймар, Ивановка, Яңа Мамонино, Иске Тура, Шушар авыллары;

Шәпше авыл җирлеге: Шәпше (административ үзәк), Кызыл Шәрекъ, Тимошкино авыллары;

Ямаширмә авыл җирлеге: Ямаширмә (административ үзәк), Олы Ялан, Здоровый Ключ авыллары.";

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Биектау муниципаль.районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| *25(10) - 3(11)* | - Марий Эл республикасы |
| *3(11) - 36(47)* | - Әтнә муниципаль районы |
| *36(47) - 67(46)* | - Арча муниципаль районы |
| *67(46) - 69(44)* | - Питрәч муниципаль районы |
| *69(44) - 38(43)* | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| *38(43) - 25(10)* | - Зеленодольск муниципаль районы |

“Биектау муниципаль районы”
муниципаль берәмлеге составына керүче авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Айбаш авыл җирлеге |
| 2 | Алан-Бәксәр авыл җирлеге |
| 3 | Әлдермеш авыл җирлеге |
| 4 | Каенлык авыл җирлеге |
| 5 | Бөреле авыл җирлеге |
| 6 | Олы Битаман авыл җирлеге |
| 7 | Олы Кавал авыл җирлеге |
| 8 | Биектау авыл җирлеге |
| 9 | Дачный авыл җирлеге |
| 10 | Дөбъяз авыл җирлеге |
| 11 | Иске Казан авыл җирлеге |
| 12 | Казаклар авыл җирлеге |
| 13 | Красносельский авыл җирлеге |
| 14 | Коркачык авыл җирлеге |
| 15 | Мәмдәл авыл җирлеге |
| 16 | Мүлмә авыл җирлеге |
| 17 | Алат авыл җирлеге |
| 18 | Семиозерка авыл җирлеге |
| 19 | Суыксу авыл җирлеге |
| 20 | Ташлы Кавал авыл җирлеге |
| 21 | Усад авыл җирлеге |
| 22 | Чыпчык авыл җирлеге |
| 23 | Чернышевка авыл җирлеге |
| 24 | Шәпше авыл җирлеге |
| 25 | Ямаширмә авыл җирлеге |

”;

3) 5 нче кушымтада:

а) икенче абзацта “, Чернышевка һәм Чыршы” сүзләрен “һәм Чернышевка” сүзләренә алмаштырырга;

б) алтынчы абзацта “Дөбъяз һәм Чыршы” сүзләрен “Каенлык һәм Дөбъяз” сүзләренә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлдермеш авыл җирлеге чиге Каенлык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км, сынык сызык ясап, “Исләйтар урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буенча, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге

буйлап, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 850 м көньякка таба, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буенча 50 м көньяк-көнчыгышка таба, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, “Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә” – Шуман автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сола елгасына кадәр бара, 1,7 км шушы елга агымы буенча аска таба Әлдермеш, Каенлык һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимофеевка авылыннан 300 м көньякта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.”;

4) 6 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Биектау муниципаль районы” муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында”
Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта

**Биектау муниципаль районының**
**“Каенлык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама “Каенлык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын (“Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Каенлык авыл җирлеге Әлдермеш, Дөбъяз, Ташлы Кавал, Усад авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы белән чиктәш.

**Биектау муниципаль районының**
**“Каенлык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге**
**территориясе чиге**

Каенлык авыл җирлеге чиге Әтнә муниципаль районы белән чиктәш җирдә Каенлык, Дөбъяз авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан

урында Олы Солабаш авылыннан 2,4 км төньякта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Биектау муниципаль районы чиге буйлап Каенлык, Ташлы Кавал авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олыяз авылыннан 1,0 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Каенлык авыл җирлеге чиге Ташлы Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 690 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Черкаска елгасына кадәр уза, 400 м шушы елга агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган урынга кадәр бара, аннары 1,2 км шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көнбатышка таба 110 м ермак буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 270 м көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба һәм 650 м көньякка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатыш юнәлештә "Исләйтар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 92, 64 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча 780 м, 260 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 31 м ермакның көньяк чиге буйлап, Крылай елгасын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 540 м урман полосасының көньяк чиге буйлап һәм 2,4 км урман полосасы буйлап бара, аннары көньякка таба 994 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнбатышка таба, 330 м көньякка таба бара, аннары көнчыгышка таба 1,3 км урман полосасының көньяк чиге буйлап башка урман полосасы белән кисешкән урынга кадәр бара, шуннан соң уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км урман полосасының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Каенлык, Ташлы Кавал һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Өнсә авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Каенлык авыл җирлеге чиге Усад авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 33 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 520 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, 140 м көньяк-көнбатышка таба Инсинка елгасына кадәр бара, аннары 60 м шушы елга агымы буенча аска таба елгага кибеп баручы инеш койган урынга кадәр, шуннан соң 2,2 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, 650 м төньяк-көнбатышка таба "Исләйтар урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 80 нче урман кварталының көнчыгыш почмагына кадәр бара, шуннан соң 1,6 км шушы урман кварталының көнчыгыш, төньяк һәм көнбатыш чикләре буйлап инешкә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча аска таба 450 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатыш юнәлештә 2,5 км озын чокырның көньяк-көнчыгыш кырые буйлап Әлдермеш, Каенлык һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимофеевка авылыннан 300 м көньякта урнашкан 32 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Каенлык авыл җирлеге чиге Әлдермеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Әлдермеш, Каенлык һәм Чыршы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чыршы авылыннан 1,8 км көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 1,9 км, сынык сызык ясап, “Исләйтар урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 200 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 900 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 850 м көньякка таба, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба, Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,6 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, “Каменка – Дөбъяз – Олы Әтнә” – Шуман автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Сола елгасына кадәр бара, 1,7 км шушы елга агымы буенча аска таба 32 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Каенлык авыл җирлеге чиге Дөбъяз авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Сола елгасы агымы буенча аска таба 1,8 км шушы елгага кибеп баручы инеш койган урынга кадәр уза, шуннан соң 270 м кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 70 м чокыр буйлап, 45 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 90 м көньяк-көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 490 м “Исләйтар урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 40 нчы урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары шул ук юнәлештә 60 м чокыр буйлап уза, шуннан соң көнчыгышка таба 640 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 660 м урман полосасының төньяк чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 430 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 800 м урман полосасы уртасы буйлап, 2,3 км урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң уртак юнәлештә көньякка таба 800 м “Исләйтар урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 50 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 140 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 160 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 430 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 110 м “Исләйтар урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 91 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекнең төньяк чиге буйлап, Сола елгасын кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м көньяк-көнчыгышка

таба, 180 м көньяк-көнбатышка таба, 130 м көнбатышка таба, 300 м көньяк-көнбатышка таба, 250 м төньяк-көнбатышка таба, 220 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 360 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 430 м көнбатышка таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 390 м төньяк-көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 830 м көнбатышка таба, аннары шул ук юнәлештә 91 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекнең көньяк чиге буйлап 370 м, Касыймов инешен кисеп үтеп, 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Каменка – Дөбъяз - Олы Әтнә автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,3 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап “Исләйтар урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының төньяк почмагына кадәр, 1,8 км көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.”;

5) 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Биектау муниципаль районы” муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында”
Татарстан Республикасы Законына
7 нче кушымта

**Биектау муниципаль районының**
**“Бөреле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама “Бөреле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын (“Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Бөреле авыл җирлеге Биектау, Красносельский, Мүлмә, Ташлы Кавал, Усад, Чыпчык һәм Шәпше авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Биектау муниципаль районының**
**“Бөреле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге**
**территориясе чиге**

Бөреле авыл җирлеге чиге Биектау авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бөреле, Биектау һәм Шәпше авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимошкино авылыннан 2,2 км көньякта урнашкан 62 нче тоташу ноктасыннан алып уртак юнәлештә көнбатышка таба 2,3 км “Шәһәр яны урманчылыгы” Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 121, 120 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,4 км шушы урманчылыктагы 120, 186 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,8 км шушы урманчылыктагы 186, 127, 134 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 790 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 460 м шушы инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м төньяк-көнбатышка һәм 1,9 км төньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң урман массивының көнчыгыш чиге буйлап 330 м төньяк-көнчыгышка таба, 510 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 290 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 560 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 425 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 330 м урман массивының көньяк чиге буйлап, аннары 470 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатыш юнәлештә 1,8 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шушы кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба 2,1 км бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 1,2 км Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап уза, шуннан соң төньякка таба 140 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр бара, аннары 200 м шушы кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба Бөреле, Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Калинино авылыннан 550 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 60 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Бөреле авыл җирлеге чиге Красносельский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бөреле, Красносельский һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Чубар авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 3,8 км “Шәһәр яны урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биектау участок урманчылыгындагы 54, 57, 70 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 320 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 60 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Бөреле авыл җирлеге чиге Усад авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бөреле, Ташлы Кавал һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Крылай елгасы үзәнендә Туктамыш авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып Крылай елгасы агымы буенча аска таба 240 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 670 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 740 м “Шәһәр яны урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 820 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 460 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км шушы урманчылыктагы 13, 169, 16 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 360 м Крылай елгасы агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр бара, шушы

инешнең агымы буенча өскә таба 1,6 км уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 415 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,5 км урман полосасы буйлап, 140 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 15 нче урман кварталына кадәр бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 850 м шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап шушы урманчылыктагы 17 нче урман кварталына кадәр бара, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 720 м шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м төньяк-көнчыгышка таба, 43 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба, 370 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, аннары шул ук юнәлештә 50 м "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 173 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекнең көньяк чиге буйлап инешкә кадәр бара, шуннан соң 50 м шушы инеш агымы буенча аска таба башка инеш белән кушылган урынга кадәр бара, көньякка таба 920 м шушы инеш буенча уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 195 м төньяк-көнбатышка таба, 530 м көнбатышка таба, 285 м көньяк-көнчыгышка таба, 160 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң көнчыгышка таба 120 м күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 1,0 км күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң уртак юнәлештә көнбатышка таба 890 м ерганак буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 650 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 350 м шушы урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм уртак юнәлештә көнбатышка таба 1,0 км көньяк чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 195 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча өскә таба 1,8 км уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 240 м көньяк-көнбатышка таба һәм 160 м көньяк-көнчыгышка таба 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Бөреле авыл җирлеге чиге Ташлы Кавал авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бөреле, Мүлмә һәм Ташлы Кавал авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташлы Кавал авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 34 нче тоташу ноктасыннан алып уртак юнәлештә төньяк-көнбатышка таба 1,1 км "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 6 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 280 м көньяк-көнбатышка таба, Олы Әтнә – Чыпчык автомобиль юлын кисеп үтеп, 400 м көнбатышка таба, Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле станциясе автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,4 км төньяк-көнбатышка таба Шемяковка елгасына кадәр бара, 850 м шушы елга агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 220 м төньяк-көнбатышка таба, 290 м көньяк-көнбатышка таба, 1,1 км төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң, юнәлешен үзгәртмичә, 720 м урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 115 м көньяк-көнбатышка таба, 1,0 км

төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 350 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 430 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр бара, 180 м шушы инеш агымы буенча аска таба аның Крылай елгасына койган урынга – 35 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бөреле авыл җирлеге чиге Мүлмә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 34 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 300 м "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 7 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 70 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бөреле, Мүлмә һәм Чыпчык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташлы Кавал авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бөреле авыл җирлеге чиге Чыпчык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 48 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатыш юнәлештә 470 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Олы Әтнә – Чыпчык автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,9 км урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м урман массивы буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, 314 м көньякка таба, 960 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,1 км шушы инеш агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 180 м көньяк-көнбатышка таба, 60 м төньяк-көнбатышка таба, 61 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң уртак юнәлештә төньяк-көнбатышка таба 3,5 км "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 20, 18 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 3,2 км шушы урманчылыктагы 18, 19, 23 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң уртак юнәлештә төньяк-көнбатышка таба 1,4 км шушы урманчылыктагы 22 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 1,5 км шушы урманчылыктагы 22, 21 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км шушы урманчылыктагы 21, 24 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Казансу елгасына кадәр уза, 1,6 км шушы елга агымы буенча аска таба бара, шуннан соң Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле станциясе автомобиль юлы буйлап 170 м көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба, 540 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 170 м күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле станциясе автомобиль юлын кисеп үтеп, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 280 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, көньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 270 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Малмыж автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,6 км урман полосасы буенча, 190 м озын чокыр буйлап инешкә кадәр

бара, инеш агымы буенча өскә таба 250 м Бөреле, Чыпчык һәм Шәпше авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимошкино авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 63 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бөреле авыл җирлеге чиге Шәпше авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 63 нче тоташу ноктасыннан алып инеш агымы буенча өскә таба 460 м уза, шуннан соң "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 106 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба, 190 м көньяк-көнбатышка таба, 40 м төньяк-көнбатышка таба, 60 м көньяк-көнбатышка таба бара, аннары төньяк-көнбатышка таба 215 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 200 м шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап уза, шуннан соң уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 990 м шушы урманчылыктагы 66 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 505 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 290 м Тимошкино авылының көнбатыш чиге буйлап, 106 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 50 м "Шәһәр яны урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 167 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 60 м буаның төньяк чиге буйлап бөягә кадәр һәм 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 140 м көньяк-көнчыгышка таба, 10 м көньякка таба, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 230 м Тимошкино авылының көнбатыш чиге һәм көньяк-көнчыгышка таба 340 м көньяк чиге буйлап уза, аннары 167 нче урман кварталының чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба 190 м һәм уртак юнәлештә көньякка таба 2,1 км 62 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

6) 10 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Биектау муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында"
Татарстан Республикасы Законына
10 нчы кушымта

**Биектау муниципаль районының**
**"Биектау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Биектау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын ("Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Биектау авыл җирлеге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Бөреле, Красносельский, Шәпше авыл җирлекләре һәм Питрәч муниципаль районы белән чиктәш.

**Биектау муниципаль районының**
**"Биектау авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чиге**

Биектау авыл җирлеге чиге Казан шәһәре муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Березовка поселогыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта урнашкан 55 нче тоташу ноктасыннан алып Биектау муниципаль районы чиге буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Биектау авыл җирлеге һәм Питрәч муниципаль районы чикләре тоташкан урында Эстачи авылыннан 2,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 69 нчы (44 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

